**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 25 декабрендәге 5344 номерлы карары**

# «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен Казан шәһәренең автомобиль юлларыннан карны кабул итү һәм эшкәртү хезмәтләренә тарифларны раслау турында

Казан шәһәре Думасының 2006 елның 20 апрелендәге 9-8 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләре һәм учреждениеләре товарларына, эшләренә һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләр, тарифлар билгеләү тәртибе турында»гы карары (үзгәрешләр белән) нигезендә, кышкы чорда юлларны нормативлар буенча карап тотуны тәэмин итү һәм Казан шәһәрендә санитар-экологик вазгыятьне яхшырту максатыннан **карар бирәм**:

1. «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен Казан шәһәренең автомобиль юлларыннан карны кабул итү һәм эшкәртү хезмәтләренә тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәләхетдинов) кышкы чорда юлларны нормативлар буенча карап тотуны контрольдә тотарга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 15 октябрендәге 2668 номерлы«“Водоканал” муниципаль унитар предприятиесе һәм “Горводзеленхоз” тресты муниципаль унитар предприятиесе өчен Казан шәһәренең автомобиль юлларыннан карны кабул итү һәм эшкәртү хезмәтләренә тарифларны раслау турында»гы карарын 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.В.Куляжевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 25 декабрендәге
5344 номерлы карарына
кушымта

**«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе өчен
Казан шәһәренең автомобиль юлларыннан карны кабул итү
һәм эшкәртү хезмәтләренә тарифлар**

| Предприятие | Кар эретү пунктының урнашу урыны адресы | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Өстәмә бәягә салымны исәпкә алып, бер тонна кар өчен тариф |
|---|---|---|---|
| «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе | Воровский урамы - Короленко урамы | 16:50:110101:768 | 250,0 |
| | Порт урамы (1) | 16:50:012002:8 | |
| | Порт урамы (2) | 16:50:012002:4 | |
| | Несмелов урамы | 16:50:000000:4174 | |
| | Васильченко урамы | 16:50:310102:182 | |
| | Тула урамы – Техника урамы | 16:50:080114:35 | |
| | Җиңү проспекты | 16:50:060201:597 | |
| | Гадел Кутуй урамы | 16:50:060403:188 | |

_______________________